ТАТАРСТАН
ВЕТЕРАНЫ

№ 7–8
17 май, 2022 ел

РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

БОЛГАРГА СӘЯХӘТ
Өлкәннәр тәҗрибә уртаклашты
> 3

ҮРНӘК ГАИЛӘ
Фатыйховлар 68 ел бергә
> 6

ФАЙДАЛЫ КИҢӘШЛӘР
Үләннәр җыеп калыгыз
> 8

БЕЗНЕҢ КАҺАРМАН

Бөек Җиңүгә – 77 ел

Иске Зәйдә яшәүче Василий Емелинны белмәгән кеше юктыр. Искезәйлеләр диңгезче, нефтьче булып хезмәт куйган 96 яшьлек сугыш ветераны белән горурлана.

Василий Емелин сугышка 1942 елда алына. Ютазы хәрби комиссариатыннан – Калугага, аннан ат олауларында фронтка озатыла.

– Сугышның нәрсә икәнен мин Калугада аңладым. Анда беренче чирканчык алдым: өскә бомба яуганда, шуның камалышында калдым. Ничек исән калганымны үзем дә белмим, – дип искә ала ул.

Таза бәдәнле авыл егете була ул, шуңа да аны 1943 елда Кара диңгез флотына билгелиләр. Бирелә ул моторчы булып хезмәт итә. Шулай итеп, яшь диңгезче җилкәсенә зур җаваплылык төшә. Ул двигатель төзеклеген тәэмин итә.

– Эшем үтә җаваплы иде. Двигательне карамыйсың икән, бөтен команда эшен юкка чыгарасың дигән сүз. Безнең бурыч дошманның су асты көймәләрен аулау иде, – ди Василий Петрович.

Ә менә Севастопольдә алар командасына «Малютка» су асты көймәсен саклау бурычы йөкләнә. Алар әлеге көймәне саклап кала калуын, тик катерга зур зыян килә. Соңыннан әлеге катерда дистәдән артык тишелгән урын саный батыр сугышчы.

> 2

Мәрхәмәт

Тормыш бәхете – изге гамәлләрдә

Казанда 13 майдан 20 майга кадәр өлкән яшьтәге волонтерларны махсус курсларда укыталар. Өлкәннәр арасында волонтерлык эше 2021 елда башланып китә. Ул вакытта «көмеш» волонтер Наилә Биктимерова республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк оешмасына мөрәҗәгать итә. Шуннан соң «БИК САБР» дигән проект эшләнеп, алар Бөтенроссия бәйгесендә грант оталар.

– Әлеге проект психоневрологик интернатларда яшәүче өлкәннәрне һәм инвалидларны кайгырту эшен үз өстенә ала. Грант акчасына 20 волонтер укытылды. 2021 елда волонтерлар 6 психоневрологик интернатта булды. Өлкәннәр белән очрашулар, төрле мастер-класслар, күңелле бәйрәмнәр уздырды, – ди республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк оешмасы рәисе Хәбир Иштирәков.

Әлеге проект кирәклеген раслаган инде. Волонтерлар «Тормыш бәхете – изге гамәлләрдә» дигән девиз белән яшәсә, интернаттагылар үзләренә карата булган игътибарга рәхмәтле.

Быел укытылачак волонтерлар өлкәннәр интернатларына гына түгел, балалар приютларына да, тернәкләндерү үзәкләренә дә барып ярдәм итәчәк. Волонтерлар өлкәннәр белән дә, балалар белән дә төрле бәйрәмнәр үткәреп кенә калмый, аларны спорт уеннарына, җыр-биюгә, рәсем ясарга да өйрәтәчәк.

ҖӘННӘТ КАДЕРЕН БЕЛЕГЕЗ

Арчада яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераны Тәлгать абый Ногманов дөньяны ярата. Унынчы дистәсен вакласа да, хәтере дә яхшы, сәламәтлегеннән дә зарланмый әле.

Тәлгать абый белән дәһшәтле сугыш елларының моңсу хатирәләрен барладык. Сугыш башланганда аңа нибары 14 яшь була.

– Укый алмадым, мәктәпне ташларга туры килде, – дип көрсенә ветеран. – Сугышның беренче көннәреннән үк колхозда эшли башладым. Ничек тә булса әти-әнигә булышырга кирәк иде. Башта көлтә җыйдым, ашлык ташыдым.

1944 елда 18 яше тулмаган егетне армия сафларына алалар. Башта Ульяновск өлкәсендә хезмәт итә, аннан соң Владивостокта уку отрядында була.

– Владивостокка поездда бер ай алып бардылар безне, – ди ветеран. – Фронтка баручы эшелоннарга юл бирә идек. Алар киткәч кенә юлны дәвам иттек. Ашау юк, 2–3 көнгә бер ашханәгә алып баралар иде, анда 1 телем ипи, 2 кешегә 250 грамм солы концентраты бирәләр. Шуны пешереп ашый идек. Элеп киптергән кебек булдык.

Бөек Җиңү хәбәрен Владивостокта ишетә Тәлгать абый. Тик туган якларга тиз генә әйләнеп кайтырга насыйп булмый аңа.

– Владивостокта безне корабль хезмәтенә өйрәттеләр. Урысча бер сүз белмибез. Корабльдә бөтен исемнәр латин теләндә. Әй, күрсәтте инде язмыш, – дип истәлекләргә бирелде Тәлгать Ногманов. – Япон сугышы тәмамланып, 1–2 көн үткәч, безне Кытайга, Порт-Артурга җибәрделәр. 7 елга якын корабльдә хезмәт иттем.

Армия хезмәте 1952 елда гына тәмамлана Тәлгать абыйның. Аннан соңгы еллар да җиңелләрдән булмый. Туган авылына кайткач, бер ел клуб мөдире булып эшләп ала ул. Аннан соң Казахстанга китеп, машина төзелеше заводында эшли. Язмыш Тәлгать абыйны шахтага да ташлый. Анда дүрт ел эшли. Бирәдә ул үзенең гомерлек ярын очрата. Зәй кызы Гөлсинә белән тормыш корып җибәрә алар. Шахтада бераз мая туплагач, гаилә туган якларга кайтып урнаша.

– Шахтада эшләгән акчага Арчадан шушы йортны сатып алдым, – ди Тәлгать абый. – Ниятем изге иде. Әти-әнине үз яныма алып, шушында тәрбиялисем килде. Гаиләдә өч кыз арасында бердәнбер ул буларак, мин моны үземнең бурычым дип санадым. Тик өлгерә генә алмадым. Әти дә, әни дә китеп бардылар.

Кызганыч, бүген гомер иткән тормыш иптәше дә янәшәсендә юк инде. Гөлсинә апа моннан биш ел элек вафат булган.

30 елдан артык коммуналь хуҗалыкта шофер булып эшли Тәлгать Ногманов.

– Нинди генә эшләргә йөртмәделәр. Каршы килә белмәдек, эшләдек тә эшләдек, – ди ул.

Тормышына шөкер итеп гомер кичерә ветеран. Бердәнбер улы Фәрит тә, әтисен карарга дип, Түбән Камадан Арчага күченеп кайткан.

– Җәннәттә яшибез, – ди ветеран. – Шуның кадерен белегез. Күгебез аяз булсын. Илебездә тынычлык булсын, сугыш афәтләре күрергә язмасын.

Резеда ХӘКИМҖАНОВА

БЕЗНЕҢ КАҺАРМАН

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Өстәвенә ике «аучы» батырыла. Шул рәвешле курку белмәс Емелин диңгез командасы составында Балаклава өчен сугыша. Моннан тыш, Севастопольне азат итүдә катнаша.

– Севастопольне азат иткән көн әле дә хәтеремдә. Дошманның тиз генә чигенәсе килмичә, безгә ракеталарны яудырды гына, – ди ул.

Шундый бер ракета Василий Петрович янына гына төшеп шартлый. Күз алдында бар да караңгылана, колактагы шауны әйтеп аңлатырлык түгел, муен буйлап ниндидер җылы сыекча ага… Капшап караса – кан… Шулай итеп, контузия алган диңгезчене Симферопольгә госпитальгә салалар. Аннан аны Севастопольгә күчерәләр.

Василий Емелинның бүләкләре күп, алар арасында ул иң саллылары һәм кадерлеләре дип Ватан сугышы, Бөек Петр, Жуков орденнарын саный. Ул 1947 елга кадәр Кара диңгез флотында хезмәт итә. Бирәдән туган ягына демобилизацияләнә.

Бескозырка, тельняшка, кара клеш чалбардан кайтып төшә ул. Хәтта диңгезче Василийны туган авылы Кырым-Сарайда танымыйча торалар.

Василий Емелин сугышта гына түгел, тыныч вакытта да каһарманлык кыла. Ул дүрт дистә елдан артык нефть тармагында армый хезмәт куя. «Татнефтегазразведка»ның Әлмәт геология-эзләнү разведкасы трестына караган Иске Зәй нефть разведкасы оешмасына бораулаучы булып эшкә урнаша. Тора-бара үз эшенең остасы булган бораулаучыга әйләнә. Тырышып, намуслы эшләүче Василий Петровичны оешма җитәкчелеге күреп алып, бораулау буенча оста итеп күтәрә. Шулай итеп, ул 30 ел әлеге җаваплы хезмәтне башкара: республикада нефть һәм газ бирүгә өметле структураларда бораулый. Ветеран нефтьче әйтүенчә, Тукай, Түбән Кама, Зәй, Әлмәт, Сарман, Минзәлә, Мөслим һәм башка районнарда урнашкан скважиналар – алар хезмәт куйган оешманың хезмәт җимешләре. Ул бер командировкадан кайтып, икенчесенә китә торган була.

– Коллектив тотрыклы, дисциплиналы, теләсә нинди катлаулы мәсьәләне хәл итәргә сәләтле иде. Киров, Башкортстан, Удмуртия якларына командировкага еш йөрдек, – дип сөйли ветеран.

Кыскасы, Емелин әлеге эшкә җаваплы булганда, скважиналар бораулау тизлеге шактый арта.

– Үз эшенең остасы иде ул Василий Емелин, эш тәҗрибәсен яшьләр белән теләп бүлешә, – ди нефть разведкасы оешмасы геологы Михаил Иванов.

Ветеран 1981 елда лаеклы ялга чыга. Гомер көзендә кызы тәрбиясендә яши.

Рәзимә КАШАПОВА

«Шушы икән инде ул – 90»

Түбән Биябаш авылында яшәүче Әминә әби Әлмөхәммәтова 90 яшьлек олы гомер бәйрәме уңаеннан, район җитәкчелеге, туганнары, якыннары янәшәсендә кабат хатирәләр яңартты, гомер һәм хезмәт юлын барлады, ерак яшьлеге турында уйланды.

Әминә әбигә Ил башлыгының Котлау хаты, район башлыгының Котлау открыткасы, бүләк һәм чәчәк бәйләме тапшырылды. Район башлыгы урынбасары Ленар Хантимиров, Шәмбалыкчы авыл җирлеге башлыгы Физзәт Миңнуллин иң изге теләкләрен җиткерделәр.

Әминә әби гомер буе колхозда хезмәт иткән. 14 яшеннән фермада сыер сауган. Сарыклар, яшь бозаулар караган, үгезләр симертүгә зур өлеш керткән. Куллары авыр хезмәт белән сөялләнгән.

– Бик күпне күрдек. Ачлыгы да, ялангачлыгы да булды. Балачактан ук нужа арбасына җигелдек. Ләкин башны имәдек. Хәзерге тормышка сөенеп яшим. Шушы икән инде ул – 90. Бер дә бу яшька җитәрмен дип уйламаган идем, – ди ул.

Әминә әби тормыш ярын авылдан гына сайлаган. Күрше егетенә кияүгә чыгып, 6 бала тәрбияләп үстергәннәр. Хәзер балаларының игелеген күреп, уллары янәшәсендә яши.

– Безнең әни – авылның иң хөрмәтле кешесе. Холкы йомшак. Беркайчан авыр сүз әйтмәде, хезмәт тәрбиясе биреп үстерде. Без аңа бик рәхмәтле. Килеп булышабыз, янынннан китеп торган да юк. Ул безгә бик кадерле, – ди кызы Фидания Җаббарова.

Әминә әбинең хәтере шәп. Үткәннәр турында бәйнә-бәйнә сөйли. Бер көнен дә онытмаган. Йорт тирәсендә үз-үзен йөртә, балаларына һәм оныкларына киңәшче булып тора.

– Авыр кул хезмәте белән яшәдек. Безнең буынны шул еллар чыныктырган да инде. Эшләгәндә фермабыз да беренчелеккә чыкты, үзебез дә мактадлык. Йортыбыз янып китеп, бер кат кием белән урамда калган чак та еш искә төшә. Торырга урынсыз калгач, төп йортта, 14 җан бергә яшәдек. Тырышыптырмашып, үз тормышыбызны булдырдык. Тормыш иптәшем дә җәйлы булды. Хәзерге тормышны алдагы белән чагыштырып та булмый, – ди әби.

Әминә әби үзе озын гомерле булуның серен хасияттә, тыныч күңел белән, кешеләргә карата яхшы мөнәсәбәттә яшәүдә күрә.

Ләйлә ШИҺАБИЕВА.
Апас районы

ОЧРАШУ УРЫНЫ – БОЛГАР

Күптән түгел Болгар шәһәренең мәдәният йортында Татарстан ветераннары (пенсионерлары) төбәк оешмасының күчмә президиум утырышы узды. Ул республикада яшәүче өлкәннәрнең мәдәни мирасны һәм халык традицияләрен саклавына багышланган иде.

Бирегә Татарстанның төрле районнарыннан җыелдылар. Районнар үзләрендәге ветераннар оешмасы эшчәнлеге хакында сөйләде. Өлкәннәр яшь буынга мәдәни һәм халык традицияләрен саклау һәм тапшыру өлкәсендәге эшләре турында фикерләштеләр. Өлкәннәрнең актив тормыш алып баруы хакында да сөйләштеләр.

Спас районы Куралово авыл җирлеге башлыгы Марина Федотова үз җирлекләрендә яшәүче ветераннарның нинди чараларда катнашулары, үткәргән бәйрәмнәр турында сөйләде.

– Без өлкән буынга иҗат белән шөгыльләнергә шартлар тудырабыз. Бу аларга актив яшәргә мөмкинлек бирә, тормышларына ямь һәм мәгънә өсти, – диде ул.

Иске Рәҗәп ветераннар (пенсионерлар) оешмасы рәисе Флера Хәйретдинова әтисенең эшен дәвам итә икән. Оешма 1982 елда төзелеп, аны әтисе Әхмәт Алишев җитәкләгән була. Оешмасында 257 пенсионер бар. Бөек Ватан сугышында катнашкан исән булган бердәнбер ветеран Зиннәтулла Гыйззәтуллин быелгы Җиңү бәйрәмен күрә алмыйча, 97 яшендә бакыйлыкка күчкән.

– Илебездә яшәүче халыкларның мәдәни мирасын, гореф-гадәтләрен, тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен саклауга быел аеруча зур игътибар бирәбез. Йола-бәйрәмнәрне, гореф-гадәтләрне саклауның бердәнбер юлы – аларны үткәрү. Ветераннарыбыз авыл тормышында һәрвакыт актив катнашалар. Мәдәният йортында узган бер генә күмәк чара да алар катнашыннан башка үтми. Җәй көне оештырылган өмәләрдә, мәсәлән, зиратны, су башын чистартуда алар башлап йөри. Иң матур бакча, аш-су осталары конкурслары, урам бәйрәмнәре үткәрәбез, – ди ул.

Әле үткән ел мәдәният йортында өлкән яшьтәгеләр белән онытылып бара торган «Орчык өмәсе» бәйрәмен хәтердә яңартканнар. Бу көнне йон да эрлиләр, төрле уеннар да уйныйлар, җырлар да җырлыйлар.

Кич утыру, бәет-мөнәҗәтләр кичәсе, «Каз өмәсе», «Нәүрүз», «Карга боткасы», Сабан туе һәм башка бәйрәмнәрне дә үткәрә алар. Күптән түгел, милли йолаларны саклап калу өчен, «Әбиемнең серле сандыгы» дигән чара үткәргәннәр.

– Авылыбызда талантлар һәм тырышлар бик күп. Алар ата-бабаларының гореф-гадәтләрен, традицияләрен саклыйлар. Мәсәлән, агач эшләре остасы Илфат Сәмигуллин. Ул үзенең агач эшкәртү цехында эскәмияләр, рәшәткәләр, гөл савытлары, идән һәм түбә такталары һәм башка агач эшләнмәләр ясый. Бу шөгыль аңа әтисе Сарыймнан күчкән. Равилә Мингәрәй кызы Хәмидуллина турында, ул кул эшләренә җанын бирә, дип әйтергә була. Чигү, бәйләү эшенә мәхәббәт Равиләгә әнисеннән күчкән, ул да гаилә традициясен дәвам итә, бу һөнәрнең нечкәлекләрен белә, – дип сөйли Флера апа.

Спас районы ветераннар оешмасы рәисе Татьяна Бурумова президиумга сәламәт яшәү рәвешенә кагылышлы проектларны тәкъдим итте. Аларны оешма грант акчасына тормышка ашыра.

– Без соңгы вакытта барлык проектларга да грантлар алырга тырышабыз. Күптән түгел Министрлар Кабинеты грантын оттык һәм бу акчага спорт кирәк-яраклары сатып алдык, – диде ул.

Утырышта «Халык иҗаты» бәйгесе турында да сөйләштеләр. Өлкәннәр белеп әйтә – гореф-гадәт, мәдәният, сәнгатьне бары тик буыннан-буынга тапшырганда гына саклап калырга мөмкин. Без моңа үзебез дә инандык. Бу көнне кул эшләре осталары эшләреннән күргәзмә дә оештырылган иде. Анда ни генә юк. Берәүләр шәл бәйләгән, икенчеләр күлмәк теккән, хәтта зур-зур картиналар да ясаганнар. Шунда ук кул эшләренә өйрәтү мастер-класслары да эшләде. Өлкәннәр яшьләргә йон эрләп күрсәтте.

Эшкә нәтиҗә ясап, Татарстан ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштирәков район ветераннар оешмалары рәисләренә һәм бәйгедә җиңүчеләргә бүләкләр тапшырды.

Хезмәтенә күрә – хөрмәте

Заһит абый турында безнең төбәктәгеләр: «Зарлана белми торган Заһит», – диләр. Дөресе дә шулай: нинди генә хезмәттә, нинди генә вазыйфада булса да, ул зарлануның ни икәнлеген белми, тырышып, җиренә җиткереп эшләү аның канына сеңгән.

Тантанага кайткан яшьтәше, бүген Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында ветераннар советы рәисе Марс Алиев та нәкъ менә аның – Заһит Җәмил улының хезмәт кешесе өчен үтә кирәкле күркәм сыйфатларга ия булуына басым ясады. «Югары белем алганнан соң хезмәт эшчәнлеген «Гигант» хуҗалыгында башлаган, аннан К.Маркс исемендәге колхозда партия оешмасы секретаре, «Волга», «Правда» колхозларында хуҗалык рәисе булган дустыбыз, игенчелек-терлекчелекне үстерү белән бергә, авыл кешесенең тормыш-көнкүрешен яхшырту буенча да күләмле эшләр башкарды, юллар, күперләр төзеде, мәчетләр корды, йортлар салды. Ул һәрьяктан мактаулы иде, аны үрнәк ителәр, аннан өйрәнделәр», – диде һәм министрлыкның Мактау грамотасын тапшырды. Заһит аганың хәләл җефете Гүзәл апага да бик күп мактау, рәхмәт сүзләре җиткерелде.

55 яшьлек юбилее белән тәбрикләнүче Гөлия апаның да исеме җисеменә бик тәңгәл килеп тора. «Ышанычлы, тугрылыклы, куркусыз, тыныч», – дигән мәгънәне аңлата икән бу исем. Гөлия апа Иске Тинчәледә урта белем алгач, техникумда укый, балалар бакчасында эшли. Бу сөйкемле кызны балалар да, коллектив та бик тиз үз итә. Аннан соң кибеттә эшләп ала, 2005 елда инде ветеринария белгечлегенә ия кызны «Волга» колхозына ферма мөдире итеп билгелиләр.

Хәзер ул Иске Тинчәле авыл җирлеге башлыгы, оста оештыручы, кайгыртучан, сабыр, йомшак күңелле җитәкче.

Туган көннәр бәйрәме, әлбәттә, җыр-моң белән аралашып барды, юбилярлар өчен дә, авылдашлар өчен дә истә калырлык булды. Безнең якларда ул шулай гадәткә кергән инде. Хезмәт кешесен күрү, тырышлыгын бәяләү – һичшиксез, кирәкле, изге гамәл.

Эльмира КРАСНОВА

ХӘТЕР МӘҢГЕЛЕК

Туган авылым Кармышта Дан орденының тулы кавалеры Ярхәм Бикчәнтәев исемендәге парк бар. Күптән түгел авыл китапханәсендә аның 100 еллыгы уңаеннан зур чара узды. Бәйрәмне китапханәчебез Резидә Төхвәтуллина оештырган иде.

Ярхәм Бикчәнтәев 1922 елның 1 июлендә колхозчы гаиләсендә туа. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, туган колхозында эшли. 1942 елда Кызыл Армиягә алына һәм март аенда, укчы буларак, фронтка элэгә. 4 нче Украина фронтында 3 нче гвардия армиясе 259 нчы укчы дивизиянең 549 нчы полкында хезмәт итә.

1944 елның 9 маенда Севастополь шәһәре өчен барган сугышта автоматчы Ярхәм Бикчәнтәев уннан артык гитлерчыны юк итә. Танкка каршы гранаталар белән өч ут ноктасын туздыра. Разведчиклар төркеме белән дошман тылына үтеп кереп, көтмәгәндә автомат-пулемет уты ачып, күп фашист солдатын сафтан чыгаралар, шуның белән Мекензиевы Горы станциясе тирәсендәге укчы подразделениенең уңышлы һөҗүменә ярдәм итәләр.1944 елның 20 маенда Ярхәм абый икенче 3 нче дәрәҗә Дан орденын ала. 2 нче дәрәҗә Дан орденын ул 1 нче Балтыйк буе фронтында 2 нче гвардия армиясе 24 нче гвардия укчы дивизиясенең 72 нче гвардия укчы полкында укчы буларак Литваның Шауляй шәһәре өчен барган сугышларда батырлык күрсәткәне өчен ала.

1943 елның 23 декабрендә Запорожье өлкәсе Орехов районының Новотроицкое авылы тирәсендә сугышның кискен мизгелендә Ярхәм солдатларны штык һөҗүменә күтәрә һәм үзе беренче булып дошман траншеясына барып җитә. Бәрелештә унга якын гитлерчыны юк итә. Бу батырлыгы өчен 1944 елның 18 гыйнварында Ярхәм абый 3 нче дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә.

Старшина Ярхәм Бикчәнтәев сугыштан соң армия сафларында кала.Ул 1946 елда гына өенә әйләнеп кайта. Дан орденнарыннан тыш, сугыш ветераны Кызыл Йолдыз, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, күп медальләр белән бүләкләнә.

Туган җирендә совхозда эшли. Ярхәм абый Сания исемле кызга өйләнеп, биш бала тәрбияләп үстерәләр.

– Әти бик әйбәт кеше иде, безгә гел үрнәк булды. Әни белән матур гомер иттеләр, – ди кызы Әминә.

Равилә МӨБАРӘКШИНА.
Чуашстан,
Козловка районы Кармыш авылы

«Утлы дуга» батыры

Без, авыл малайлары, кечкенәдән үк күршебездә генә үзенең фидакарьлеге белән танылган Кәлимулла абый Хәбибуллинны беренче герой итеп, аңа охшарга тырышып үстек.

Аның белән соңгы тапкыр редакциядә очрашып сөйләшеп утырдык. Кәлимулла абый дәһшәтле Курск дугасында танклар армадасында барган каты бәрелешләр вакыйгасын сөйләгән иде.

– 1943 ел иде, – дип хәтеренә төшерде ул. – Орел – Курск юнәлешендәге тиңдәшсез операциядә җиңеп чыгар өчен дошман бөтен көчен куйды, тик меңәрләгән «Тигр»лары бер-бер артлы сафтан чыга торды.

Җәйге кич. Безнең танк бригадасына Острогорск пунктын алу йөкләнде. «Т-34» танклары белән тоташ броня булып килүче «Тигр»лар өстенә ыргылдык. Тирәякны ут, сөрем әйләндереп алды.

Менә Кәлимулла Хәбибуллин һәм укчы сержант Яков Корбун идарә итә торган танк алга ыргылып, «Тигр»лар арасында кала. Алар туры наводка белән бер-бер артлы дошман танкларын яндыралар. Ләкин көтмәгәндә алар аткан снаряд читтә ярыла. Корбунга: «Маңгаена төзә, маңгаена!» – дип кычкыра Хәбибуллин. Ул арада бер «Тигр» өскә ыргыла.

– Шулвакыт дошман танкының маңгаен чәрдәкләдек, – дип дәвам итте сүзен өлкән танкист Кәлимулла. – Тик ул һаман өскә килә. Корбунның: «Бронясы калын, снаряд кына файдасыз», – дигән сигналы колакны яра. «Таранга барабыз!» – дип кычкырганымны да сизмичә, без куәтле «Тигр» өстенә ыргылдык. Фашист кача башлады. Корбун аңа яңадан яндыргыч снаряд җибәрде һәм дошман «ташбака»сы кара сөрем эчендә калды. Тик бу вакытта безне башка танклар кысрыклый иде. Берсен таранга алып, җимереп узды к. Тагын «Тигр» килеп чыкты. Үземне белештермичә, танкны сулга бордым. Дошман танкының чылбыры өзелде. Ә икенчесе, моны күрүгә, борылып качу ягын карады. Безне алда исә тагын утлы яу көтә иде. Җир тетри, безгә калтыраргамы? Юк, артта уттан теткәләнгән җир. Өч немец танкы безне кысрыклап килә.

– Ут! – дип команда бирәм. «Тигр»га өч мәртәбә атуга, ялкын ялмады.

– Броня тишә торган снаряд белән ут! – дип кычкырам. «Тигр»ның нәкъ бензин багына эләкте. Көтмәгәндә немец самолетлары килеп чыкты. Бер снаряд нәкъ безнең өстә ярылды. Люкны ачып, җиргә сикердек. Бомба чокырына туры килдек. Дошман чигенде, «Ура!» тавышлары яңгырады.

Бу батырлыгы аның Кызыл Байрак ордены белән билгеләп үтелә.

– Безгә тагын да җаваплырак бурыч йөкләнде, – дип сөйли Кәлимулла абый. – Ковель шәһәре өчен барган сугышларда безнең бригада тиңсез батырлыклар күрсәтте. Оборона вакытында фашистлар бик нык урнашып калганнар. Кая карама – мина кырлары. Безнең ротада минем танк алдына өч метр озынлыгында мина эзләгеч көйләнде. Танклар минем арттан үлем кырына ыргылдылар. Кырыйдан арттарак калып, җиде танк саклап бара үземне. Дошман машиналары яндыргыч снарядлар белән безне көл итәргә теләде. Тик без һаман алга омтылдык, шәһәрне азат иттек.

Бу батырлыгы өчен механик-йөртүче старшина Хәбибуллинның күкрәгенә Кызыл Йолдыз ордены тагыла.

Ул шулай, танкист буларак, Берлинга барып җитә, рейхстаг стенасына исемен уеп яза. Туган авылы Югары Стәрлегә кайтканда аның күкрәгең дүрт орден, җиде медаль бизи. Әйе, «Тигр»ларны изгән батырның батырлыгы легенда булып калырлык. Чын мәгънәсендә Советлар Союзы Герое булырлык кеше ул! Тикмәгә генә аның «Т-34»е белән горур басып торган сурәтен «Огонек» журналының тышкы битенә бастырмадылар!

Кәлимулла абый аннары озак еллар авыл Советы башкарма комитеты рәисе булып эшләде, ә хатыны Зәйтүнә апа башлангыч классларда безнең кебек күп балаларны укытып-тәрбияләп үстерде. Уллары Нәфис, кызлары Зимфира белән бергә тәгәрәшеп үсеп, тормышта да лаеклы урыннарыбызны таптык.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы Югары Стәрле авылы

ҖЫРЛАП ЯШИК!

Казанда ветераннарның үзешчән башкаручылар арасында үткәрелгән җиденче «Балкыш» республика фестиваленең гала-концерты узды. Быел әлеге фестиваль Татарстан ветераннар (пенсионерлар) оешмасы оешуга 35 ел тулуга багышланган иде. Шулай ук быел «Балкыш» оешканга да 10 ел тулды.

Концертны Дәүләт Советы Рәисе, «Балкыш» фестиваленең оештыру комитеты рәисе Фәрит Мөхәммәтшин тамаша кылды.

– Фестиваль хәрәкәте дистә ел эчендә зур иҗади җыенга, республиканың «визит карточкасы»на әйләнде, – диде парламент башлыгы. – Ә иң мөһиме – мондый чаралар үткәрүдә сез үзегез башлап йөрисез.

Фәрит Мөхәммәтшин өлкән буынны Татарстанның «алтын фонды» дип атады.

– Хәрәкәттә булу, күңелегез белән һәрвакыт яшь булып калу, һәрдаим иҗатка омтылу, республика халыкларының мәдәнияте һәм традицияләрен саклауга үзегездән эчкерсез өлеш кертү, яшьләргә тәҗрибә тапшыру теләге зур хөрмәт уята һәм барлык хакимият баскычларында хуплау таба, – диде ул.

Дәүләт Советы Рәисе бүген бердәмлекнең кирәклеген дә искә төшерде.

– Безнең республика, кыенлыклар килеп туганда, һәрвакыт бердәмлеге белән аерылып тора, – диде ул. – Татарстан мәҗбүри күченеп килгән 1,5 меңнән артык кешене кабул итте. Мондый вакытта сабырлык һәм бердәмлекне саклау, игелек һәм мохтаҗларга ярдәм кулы сузу бик мөһим. Бу мәсьәләдә өлкән буынның роле гаять зур. Сезнең зирәклек, рухи көч һәм ныклыгыгыз, дустанә ярдәмегез һәм шәхси үрнәгегез яшьләргә теләсә нинди кыенлыкларны җиңәргә, илне яңа үсеш баскычларына чыгарырга ярдәм итәчәк.

Татарстан ветераннарының (пенсионерларның) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштирәков «Балкыш» фестивален көтеп торучы өлкәннәр күп булуын әйтте. Район-авылларга барганда, фестиваль кайчан була, дип сорыйлар икән.

– «Балкыш» фестивале – өлкәннәр өчен чын бәйрәм! Ун ел эчендә фестиваль республиканың мәдәни тормышында лаеклы урынын тапты, танылды һәм татарстанлыларның мәхәббәтен яулады, – ди. Аның сүзләренчә, беренче фестиваль 3,5 меңгә якын катнашучыны җыйган булса, җиденче чарада 25 мең ветеран катнашкан. Казанда әле тагын ике концерт узачак. Аның берсе 25 май көнне – Ленин исемендәге мәдәният йортында, икенчесе көзгә таба үткәрелер дип көтелә.

Лариса САМОЙЛОВА, «Балкыш» фестивале лауреаты:
– Үземне сәхнәдән башка күз алдына да китерә алмыйм. Фестивальне көтеп алам. Ел әйләнәсе җыр белән мин. Ветераннар хорында җырлыйм.

Наталья ЧЕПКАСОВА, «Балкыш» фестивале лауреаты:
– Сәхнәдә кайчак каушыйм да. Әмма монда кимчелекне йөзеңә бәреп әйтүче, күңелне төшерүче юк. Шунысы рәхәт. Әгәр тамашачы алкышлый икән, безгә шул җитә. Әлеге фестивальне оештыручыларга зур рәхмәт. Сәхнәгә менүгә яшәрдек, яңадан яши башладык.

ЙӘ ӨЙЛӘНӘСЕҢ, ЙӘ СЫЕРНЫ ҮЗЕҢ САВАСЫҢ!

68 ел бергә иңне-иңгә куеп гомер итүче үрнәк, матур гаиләнең бер-берсенә юл биреп, әкрен генә тормыш йомгагын сүткәннәрен тыңлап утыру гына да күңелгә сары май булып ята. Ә гомер елгасы бормалы бит, төрле вакыт булган: ачлык-ялангачлык, ятимлек, тик әлеге авырлыклар аларның күңел көрлеген сындыра алмаган.

Өлкәннәрнең икесе дә – Кәркәүч авылында туып-үскән сугыш чоры балалары. Аларга хәзерге заман сабыйлары кебек иркәләнеп үсәргә мөмкинлек булмаган, башка яшьтәшләре белән бергә бик иртә тормыш йөген тарта башлаганнар. Язын колхоз басуыннан өшегән бәрәңге эзләгән, җәен болыннардан ат һәм куян кузгалагы, акбаш, кәҗә сакалы, кычыткан җыйган вакытларын әле дә моңсуланып искә алалар.

Фәния һәм Тимерхан Фатыйховлар – тыл ветераннары. Туган якларын калдырып читкә чыгып китү турында уйлап та карамаганнар, дөресен генә әйткәндә, моның өчен мөмкинлекләре дә булмаган, чөнки мәктәпне тәмамлаганнан соң, яшьләрне авылда калдыру өчен, паспортларын кулга бирмәгәннәр.

– Ул вакытта авыл зур иде, без ике сыйныфта егерме бишәр бала белем алдык. Өс-баш, тамак ныклыгы бөтенебезнең бертөрле иде, шуңа күрәме, бик тату булдык. Җиденче сыйныфны тәмамладык та колхозга эшкә килдек, ә аңа кадәр дүрттә укыганда ук җәй көннәрендә өлкәннәргә булыша идек, читтә калмадык. Ферма гөрләп торды, терлекләр күп, эш бар иде, – дип, хатирәләрен барлый алар.

Фәния апа

Фәния апа бик яшьли ятим калган, абыйсы белән җиңгәсе карамагында үскән. Кул арасына керә башлау белән колхозга эшкә чыккан.

– Әтием юк иде, әнием 42 яшендә үк үлеп китте. Рәхәт үстем дип әйтә алмыйм, кимсенүләр дә булгандыр, – диде Фәния апа, балалык елларын искә алып. – Иртән чыгып киттек, кич кайттык. Кайсы басу икәнен дә белмәдек, урак урдык, көлтә көлтәләдек, чалгысын, көрәк-сәнәген дә тоттык. Нинди эш кушсалар да, белмим, булмый, дип әйтмәдек. Мин урак урырга бик оста идем, бил бөгеп, егерме бишәр сутый җир узган чаклар булды. Басуга җәяү бардык, техника түгел, авылда велосипед та юк иде.

> Без ул тормышны начар дип уйламадык, шулай тиеш кебек кабул иттек, чөнки һәрвакыт, илебез – чәчәк аткан, алга киткән ил, дип өйрәттеләр. Шуңа күрә башка җирдә начаррак яшиләрдер дип уйлый идек. Күңелне төшермәдек, кичләрен уенда очраштык, җырладык, биедек, бәхетле идек. Әле дә сагындыра ул чаклар.

Олыгая төшкәч, кыз фермага эшкә керә, бозаулар карый. Ул вакытта хезмәт көнен калдырырга ярамый торган була. Бервакыт аны, утыз көне тулмаган өчен, Тәкәнешкә судка алып баралар.

– Без дүрт кыз идек, Тәкәнешкә кадәр 25 чакрым араны җәяүләп атладык, шулай ук кайттык. Ә колхоз рәисе яныбыздан ат белән барды, безне утыртмады. Шундый каты йөрәкле кешеләр дә булыр икән, – диде Фәния апа, авыр сулап.

– Каршы килә торган вакытлар түгел бит, «военное время» дип кенә әйттеләр, – дип сүзгә кушыла Тимерхан абый. – Бөтен эш кул көче белән башкарылды. Эшләгән өчен бер хезмәт көне язарлар иде дә берәр килограмм арпа, арыш бирерләр иде, бодае бик эләкмәде. – Сугыштан соң колхозга утын ягып йөри торган беренче трактор кайтты. Шайтан күргән шикелле аны карарга бөтен авыл җыелды. Кем йөртә икән моны, бик башлы, акыллы кешедер инде дип, бар халык шаккатты.

Тимерхан абый

Тимерхан абый мәктәптә бик әйбәт укыган, тик алга таба укуын дәвам итәргә мөмкинлеге генә булмаган. Колхозда төзелешләрдә эшләгәндә дә фоторәсеме Мактау тактасыннан төшмәгән.

– Авылда Миңнур апа бригадир иде. Миңа сыер җигеп эшкә чыгарга кушты. Әти сугышка киткәнче, ат җигәргә, тугарырга өйрәнеп калдым. Тик минә камытны кысарга гына көч җитми иде. Аны йә өлкән ат караучы, йә бригадир җайлап, рәтләп бирде. Шуннан соң кая кушалар, шунда эшлибез: тирес тә түктек, азык та ташыдык, ә үсә төшкәч, сукачылар артыннан пар ат белән тырмага чыктык, урман кисәргә дә йөрдек. Чабаталар бер атнага чыдагандыр, сатып алырга акчаң булса, яңасын аласың, йә яланаяк йөрергә туры килә, – дип сөйләде ветеран.

Тимерхан абый әтисе сугышка киткәндә кечкенә булган, ә кайтканын яхшы хәтерли. 1946 елның август ае була ул.

– Әти егәрле, таза гәүдәле кеше иде. Тик менә сугыштан бик таушалып кайтты. Ул сәламәтлеге буенча сугышка кермәгән, бик теләсә дә җибәрмәгәннәр, ачлы-туклы заводта хезмәт куярга туры килгән, – диде ветеран. – Безнең яндагы багана башыннан радио сөйли иде, аны тыңларга бөтен авыл җыелганы хәтердә, сугыш турындагы яңалыкларны шуннан белеп тордык. Ә сугыш беткәч, демонстрация булды, дыргылар уйнаттылар, барабаннар кактылар.

Фермага дип китеп, кияүгә чыга

Фатыйховлар гаиләсенең кавышу тарихы да гади, беркатлы, ничектер самими. Өйләнергә исәбем дә юк иде әле, дип елмая Тимерхан абый. Әтисе, сугыштан кайткач, йә өйләнәсең, йә үзең сыер савасың, дигән шарт куя егеткә. Чөнки әниләренең күзләре бөтенләй күрми торган була, ә йорткура тирәсендә хатын-кыз эше җитәрлек.

– Минем фермада эшләгән чак иде. Ул көнне уенга да чыкмадым. Иптәш кызлар килеп, фермага кунарга барырга чакырдылар. Ул вакытларда шулай фермада төнгә дә кала идек. Эш киемнәремне киеп, кесәмә ипи тыгып чыгып киттем. Капка төбендә Тимерхан белән иптәше басып тора. Болар да фермага төшәләрдер инде, дип уйлап куйдым. Шуннан соң гына иптәш кыз серне ачты. Нишләп Тимерханга кияүгә барыйм, башка кызлар беткәнмени аңа, дип карыштым. Мин кешедән киммени, диде Тимерхан. Өйләрендә әти-әнисе чәй куеп каршы алдылар, – диде Фәния апа, яшьлек елларын искә алып. – Дүрт малай, бер кыз тәрбияләп үстердек. Бала тапкач, кырык көн дә ял итмичә, уракка төштек. Әни сукыр булса да, балаларны үстерешергә ярдәм итте, шулхәтле йомшак телле, акыллы хатын иде, балалар да әбиләрен яраттылар, тыңладылар. Хәзер балалар үзләре әби-бабайлар инде, төрлесе төрле җиргә таралышып гомер итәләр.

Озак еллар бергә матур гомер кичерүнең сере бик гади: ачуланышырга вакыт булмады, гел эштә булдык, ди өлкәннәр. Хәзерге көндә алар уллары Мөнип белән киленнәре Илзирә гаиләсендә тыныч картлык кичерәләр.

– Аллага шөкер, тормышлар бигрәк рәхәт бит. Кукмарадагы үзгәрешләрне күреп тә шаккатабыз, чәчәк ата шәһәр. Безнең заманда ул бер авыл кебек иде: әзерләүләр конторасы, киез итек комбинаты булгандыр инде... Хәзер без анда барсак, адашыр идек, – ди өлкәннәр. – Илләр тыныч булып, матур тормышларда исән-сау яшәргә язсын.

Ризилә КОРБАНОВА.
Кукмара

Шигърият

СИРЕНЬ ЧӘЧӘГЕ

Сирень чәчәк аткач, өзеп кереп,
Утыртыр иде әни өстәлгә.
Ярата иде кәеф күтәрерлек
Бер матурлык өйгә өстәргә.

Ике яклы өйнең түр башында,
Бик кыйммәтле бүләк шикелле,
Һәр елны да пыяла банкада
Сирень торды матур чәчәкле.

Аның хуш исе таралыр иде,
Бәйрәм төсен кертеп өйләргә.
Суын алмаштырыр иде еш кына,
Өлгермәсен, диеп, шиңәргә.

Өй каршында сирень куагы
Шау чәчәктә ел да утыра.
Өй эчен дә, урамны да хәзер
Тәмле хуш исләргә тутыра.

Сиреньнәрнең матур чәчәкләре
Шундый матур, күркәм үзләре.
Шул чәчәкләр арасыннан миңа
Карый кебек әни күзләре.

КАРТЛЫККА

(Ачык хат)

Картлык, сиңа бу хатымны,
Язамын бераз алдан.
Юк-юк, көтмим әлегә сине,
Вакытың бар саналган.

Белмим, барып җитәрбезме,
Гомер – Аллаһ кулында.
Бу бары тик, сине хөрмәтләп,
Искә алу турында.

Хат язарга булдым әле,
Үтенеч, гозерләрне.
Бәхетле күрәсе килә бит
Алдагы гомерләрне.

Йөрәп торырга язсын дим,
Аяк-кул исән булып.
Сызланмыйча, сыкранмыйча,
Намазларыңны укып.

Теләк теләп, бабай белән,
Утырсаң кара-каршы,
Күз күреп, колак ишетсә,
Эшләсә тагын башы...

Тилмереп ятмасак иде,
Карап кеше күзенә.
Иманлы булсын балалар,
Догачылар үзеңә.

Балаларның, оныкларның
Игелекләрен белеп,
Әйтсәк иде, картлык килгәч,
– Әлхәмдүлилләһ! – диеп.

Аллаһыдан күп сорамыйм,
Гомернең дә артыгын.
Кеше ялыктырып тагын,
Килсә озын картлыгың...

Шуңа алда хат язарга
Булдым әле нигәдер.
Бәлки, сорасаң, яздырсаң,
Матур картлык киләдер.
Хәер,
Аны кем беләдер?..

Рушания ӘХМӘДУЛЛИНА
(ЧАНЫШЕВА)

АКЛАНГАН ӨМЕТЛӘР

Киләчәген белгән кебек, әтисе Зәки кызы Стеллага матур сүзләр язып калдыра, аның сәләтле булачагын юрый.

Репрессия чорының кырыс җилләре Зәйнәп белән Зәки Мөхсиновлар гаиләсенә дә кагыла. Гаиләнең канатлары каерыла, нахак бәлаләр тагыла, тормыш җимерелә. 1937 елда Зәки Мөхәммәтҗан улы Татгосиздат җитәкчесе булып эшли. Ихтирамга лаек кеше була ул. Шул ук елның 10 июлендә НКВД органнары тарафыннан кулга алына. Аны советка каршы эшчәнлек алып баруда гаеплиләр. «Халык дошманнары»ның атаклы төрмәсе «Черек күл»гә ябалар.

Зәйнәп төрмәгә иренең хәлен белергә килеп йөри. Үз авызыннан өзеп, иренә ризык ташый. Зәки Зәйнәпкә качырып кына хат язып чыгара: «Минем бер гаебем дә юк, озак тотмаслар, 3–4 айдан чыгарырлар. Көт мине». Ләкин бу бәхет эләкми аңа. Ни өчен утыртканнарын да белмичә, нахак бәлаләр тагылып, газаплы сорау алулардан, кимсетелүләрдән, мыскыллаулардан тәмам рухы сындырылган Зәки 1938 елның 9 маенда атып үтерелә. Сәяси репрессия корбаны буларак, үлгәннән соң гына аклана.

Ирен югалту ачысыннан айнып та өлгермәгән Зәйнәпне 16 майның караңгы төнендә кара машина белән алып китәләр. Мордовия лагерьларына илтеп тыгалар. Зәйнәп биш ел чәчәктәй гомерен тоткынлыкта уздыра.

Әнисен кулга алганда, Стеллага бары 4 кенә яшь тулган була. Аны әбисе Гыйльмибаян Кышлауга алып кайта. Кыз аны «дәү әни» дип йөртә.

– Дүрт яшемдә мин әтисез дә, әнисез дә калдым. Тора-бара әти хәтеремнән югалды. Ә әнине көттем, чөнки дәү әнием һәрвакыт: «Менә тиздән әниең кайтыр», – дип өметләндерә иде, – дип сөйли Стелла Зәки кызы.

Авыр биш елын үткәреп, Зәйнәп Кышлауга кайтып төшә. Әлеге көннәр Стелла апаның күңелендә шулай сакланып калган: «Бервакыт дәү әни исеменә телеграмма килеп төште: «Приезжаю, Лена». Почтада ялгыш әнинең исеме Зинаны «Лена» дип язганнар икән. Дәү әни: «Кем булыр бу?» – дип бик аптырады. Мин күршеләрдә идем, кайтсам, өйдә чит кеше утыра. Дәү әни мине алдына алып: «Кызым, бу апайны танымыйсыңмы?» – дип сорады. Без, бер-беребезгә карашып, озак кына басып тордык. Бу хатын ничектер минем күңелемнең яшерен почмагында сакланып калган кечкенә генә өмет чаткысы чагылышы иде, мин аны кайчандыр күргән кебек, ләкин һич тә исемә төшерә алмыйм. Якын да кебек, әмма шул ук вакытта бик ерак та. Дәү әнинең соравына: «Юк, мин аны белмим!» – дип җавап бирдем. Аннан дәү әни: «Бу – синең әниең бит!» – дигәч, әни белән кочаклашып елаштык. Шунда мин әнинең никадәр якын, кадерле, газиз кеше булуын аңладым. Без, бер-беребезне җибәрмичә, бик озак басып тордык. Әни, дөрестән дә, бик матур иде: коңгырт кара күзле, бөдрәләнеп торган чәчле, түгәрәк йөзле, төз гәүдәле, чандыр. Шулай итеп без – әни, дәү әнием, мин өчәү яши башладык.

Зәйнәпне Кышлау мәктәбенә мөдир итеп куялар. Ул анда байтак еллар балаларга рус теленнән дәресләр бирә. Стелла да тәпле белемне Кышлау мәктәбендә ала. Алтынчы сыйныфтан соң, әнисен башка эшкә күчерү сәбәпле, Күгәнле җидееллык мәктәбендә укый башлый. Озакламый Зәйнәп Сөләймановны Арча мәгариф бүлегенә инспектор итеп билгелиләр. Стелла әнисе белән Арчага күченә һәм беренче номерлы мәктәптә рус классында укый башлый.

Сигезенче сыйныфта аның класс җитәкчесе Ленинградтан эвакуацияләнеп кайткан рус теле укытучысы Любовь Преображенская була.

– Искиткеч күп белүче, гаҗәеп кешелекле, яхшы күңелле, эрудицияле, «РСФСРның атказанган укытучысы» исемен алган, Ленин орденлы укытучым миндә рус теле һәм әдәбиятына мәхәббәт тәрбияләде. Урта мәктәпне яхшы билгеләренә тәмамладым. Минем алга һөнәр сайлау мәсьәләсе килеп басты. Ак халат киеп, кеше сәламәтлеген сагында эшләргә, табиб булырга хыялландым. Ләкин класс җитәкчесе үзенең яхшы киңәшләрен бирде: «Минем эздән бар, Казан педагогия институтына имтихан бир, үкенмәссең. Синнән яхшы укытучы чыгачак», – диде.

Класс җитәкчесенең киңәшен тыңлап, Стелла 1950 елда Казан дәүләт педагогия институтының рус-татар бүлегенә укырга керә. Стелла Зәки кызына укытучы һөнәренә мәхәббәт нәсел җепләре аша салынган. Сөләйман ахун шөһрәтле галим, гайрәтле һәм вәкарьле кеше була. Бик көчле дин әһеле булып, мәчет-мәдрәсәләрдә укыта. Дини белем белән бергә дөньяви фәннәр буенча да гыйлем бирә. Аның берничә фән буенча программалар төзүе дә мәгълүм.

Сөләйманның ун ир баласы булып, ул аларны укымышлы итеп тәрбияли. Бер улы Лотфулла 1872 елда Кышлауга кайтып, авыл халкына дини гыйлем бирә. Лотфулланың биш кызы да дөньяви белем һәм тәрбия ала, барысы да диярлек укытучылык эше белән шөгыльләнә. Сөләймановлар нәселе 200 елга якын халыкка хезмәт итә, аң-белем тарата. Лотфулланың оныгы Стелла да укытучылар династиясен дәвам итә. Татар баласын рус теленә өйрәтү, аңа ныклы белем бирү укытучыга зур җаваплылык өсти. Аның тырышлыгы хөкүмәтебез тарафыннан бәяләнеп, 1971 елда Почет билгесе ордены белән бүләкләнә. 1978 елда уку беткән көннәрдә аны бөтенсоюз укытучылар съездына чакыралар. Яшь буынга тәрбия һәм белем бирү өлкәсендә озак еллар армый-талмый эшләвен искә алып, Стелла Зәки кызына, Татарстан укытучыларыннан беренчеләрдән булып, Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә, Ленин ордены һәм алтын «Урак һәм Чүкеч» медале тапшырыла.

Стелла Зәкиевна үзенең мәхәббәтен дә Яңа Кенәр мәктәбендә таба. Ул – данлыклы педагог, РСФСРның Халык мәгарифе отличнигы, ТАССРның атказанган укытучысы Хәбир Габдрахманов. Ул бу мәктәптә гомере буе физика, астрономия фәннәрен укытты.

Габдрахманова Стелла Зәки кызының 85 яшьлек юбилеена «Акланган өметләр» дигән китабым нәшер ителде. Ни өчен китапка шул исемне сайладым? Кеше бу дөньяда һәрвакыт өмет белән яши. Зәки Мөхсинов, нәни кызчыгының сәләтләрен күреп, аңа киләчәктә зур өметләр баглый. Үзенең кызына сирәк очрый торган Стелла исемен куйдырганда, кечкенә йолдызчыкның (Стелла латинча йолдыз дигәнне аңлата) зур йолдызга әверелеп, бу исем аңа тормышта дөрес юлдан китәргә ярдәм итәр, башкаларга да яктылык биреп торыр дип уйлагандыр ул.

Рузалия ИБРАҺИМ.
Арча районы

Казандагы Җиңү паркының мемориаль музеенда «Буыннар элемтәсе» циклын оештыручы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ләйсән Кариева бу юлы фронтовик язучы, галим Хәмит Кавиның улы Илгизне чакырган иде. Геология фәннәре кандидаты Илгиз Кавиев гомере буена Татарстанда нефть һәм газ ятмаларын эзләгән. «Татнефтегазразведка» трестының хезмәт ветераны.



СУГЫШТАН КАЙТСАМ, ИСЕМЕН КУШАР ИДЕМ

Әтисе исә 1906 елда Чуашстанның Козловка районындагы Әлмән авылында Сәлим мулла һәм Закирә абыстай гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килгән. Казанда педагогия техникумында, аннан Көнчыгыш педагогия институтының биология бүлегендә укыган. 1936 елда физик география кафедрасы аспиранты булуы турында да белешмә бар.

– 1932 елда, 26 яшендә, әти, Идел буендагы ачлыктан качеп киткән милләттәшләр язмышы белән кызыксынып, Омск шәһәренә барып чыга, – дип искә алды Илгиз Хәмит улы. – Ул үзенең күргәннәре турында фәнни-популяр очерклар, маҗаралы хикәя-повестьлар язган. Советлар Союзының казылма байлыклар чыга торган урыннарында булган, хәтта Арктикага сәяхәт иткән. 1930 елда аның «Кавказ таулары аркылы җәяү» дигән китабы басылып чыга. 1932 елда дөнья күргән «Боз диңгезенә таба» китабында Мурманск тимер юлы һәм шәһәре, ак төлкегә бай Кильдин атавы, балык тотучылар, болан асраучылар турында сөйләнә.

Язучы унлап китап чыгара. «Идел буенда йөрү», «Балалар күмер өчен көрәшәләр», «Кузбасска сәяхәт», «Сәяхәт» һәм башкалар. 1939 елда Хәмит Кавига, Казан – Мәскәү арасында чаңгы сәяхәте оештырып, яшь буынга тәрбия бирүдәге хезмәте өчен халык комиссары имзасы куелган исемле сәгать бүләк итәләр. Авылдашларым аның, энесе Тәлгать белән Казаннан 60 чакрымны узып, берничә тапкыр кышын чаңгыда кайтулары турында сөйлиләр иде. Техникумда укытканда Хәмит Кави Әтнә районыннан Мәрьям Габдрахман кызы (ул Габдулла Тукай белән дус була) белән тормыш кора. Бөек Ватан сугышына кадәр уллары Илдар һәм Илгиз туа. Немецлар сугыш башлагач, сентябрь аенда фронтка китә. «Исән-сау кайтсам, балаларыбыз күп булыр, аларга «Ил»дән башланган исемнәр кушарбыз», – ди ул хатыны Мәрьям белән хушлашканда.

Фронтта лейтенант Хәмит Кавиев зур батырлыклар күрсәтә, медальләр белән бүләкләнә, китаплары өчен материал туплый, кыска гына ял вакытларында иҗат эшен дәвам итә. Әмма бик күп язучыларыбыз кебек хыялларын тормышка ашыра алмый.

1944 елның 15 июнендә Көнбатыш Украинаның Волынск өлкәсендәге Дружкополь дигән урында генерал-лейтенант Ватутин армиясе часте сугышчылары ял иткән вакытта бандерачылар һөҗүм башлый. Өлкән лейтенант Хәмит Кавиев җитәкләгән танк көрәшкә керә. Бандерачылар танкны яндыралар. Экипаж гомерен саклап, танк командиры Кавиев көрәштәшләрен аскы люктан чыгарып җибәрә, үзе танкта янып үлә. Шушы батырлык хакында маршал Жуковның «Хатирәләр» китабында искә алына. Кыю танкист, өлкән лейтенант Хәмит Кавиев исеме Дружкопольда туганнар каберлеге ташына уелган. Илгиз Кавиев Советлар Союзы заманында әтисе җирләнгән урыннарда берничә тапкыр була. Бу дәһшәтле вакыйгаларның шаһиты булган кешеләр белән аралаша. Кичәдә ул Украинадагы менә шул очрашулар турында да искә алды.

Равилә МӨБАРӘКШИНА

Табигать нигъмәте

Сирень

Үлекле яралар булганда, баш авыртканда, сирень яфрагын ябып торырга киңәш ителә. Чәчәкләрнең төнәтмәсе ашказаны җәрәхәте, ютәл, бөерләрдә таш булганда, салкын тигәндә файдалы. Төнәтмә ясау өчен 1 аш кашыгы чәчәкләрне 1 стакан кайнаган суда пешерергә, ярты сәгать төнәтергә кирәк. Көнгә 3–4 тапкыр 1әр аш кашыгы эчәргә.

Сирень һәм юкә чәчәкләре кушылмасыннан тирләтүче һәм температура төшерүче төнәтмә ясыйлар. Аны салкын тигәндә һәм бизгәк өянәкләрен басу өчен кулланалар. Ә сирень яфраклары төнәтмәсе бизгәккә каршы файдалы чара булып исәпләнә. Озак саклау өчен 40 градуслы аракыда 1:20 нисбәтеннән яфраклары төнәтмәсен ясарга була. Аны көнгә 3–4 тапкыр, ашар алдыннан 15–20 тамчы эчәләр.

Чәчәкләреннән ревматоид артритлар вакытында сылау өчен, сызлауны киметүче мазьлар ясыйлар: 2 аш кашыгы вакланган чәчәкләрне 2 аш кашыгы атланмай белән яхшылап бутыйлар.

vk.com

Эпилепсия белән интеккәннәргә сирень чәчәгеннән әзерләнгән чәй эчәргә киңәш ителә.



Нияз Бишбалта

ҖАВАПЛАР. Горизонталь буенча: гәләҗимеш, ачу, ләм, ару, кыяна, тур, карама, или, уйлану, оек, тал, тула, уртак, газ, шомырт.
Вертикаль буенча: галәмәт, урт, аек, Лир, егу, оту, тоз, атна, кош, лупа, миләк, мин, ачы, шаман, лар, анар, кушу, таптану.

ФАЙДАЛЫ ҮЛӘННӘР

➢**ҮГИ АНА ЯФРАГЫ** салкын тию, грипп, тын юллары авыруларыннан файдалы. Дәвалану өчен чәчәкләре һәм яфраклары кулланыла. Чәчәкләрен – майда, яфракларын июньдә җыялар.

vk.com

vk.com

➢**КЫМЫЗЛЫК (КИСЛИЦА)** гипертония һәм атеросклероздан файдалы. Гастрит, йөрәк-кан тамырлары чирләреннән дә кулланыла.

➢**ТУЗГАНАК** витаминнар, калий һәм фосфор тозларына бай. Төнәтмәсе организмны ныгыта, тынычландыра, канны чистарта, лимфа системасы ялкынсынудан ярдәм итә, организмны яшәртә, азканлылыктан файдалы.

vk.com

➢**КАРЛЫГАН.** Кара һәм кызыл карлыган яфрагыннан чәй ялкынсынуны бетерә, иммунитетны күтәрә, тынычландыра. Карлыган яфрагы төнәтмәсе йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан файдалы, эчне җиңелчә йомшарта.

➢**ЧӘЧӘКЛӘР (ШОМЫРТ, СИРЕНЬ).** Чәчәкләрне иртән чык кибүгә җыярга кирәк. Шомырт чәчәге төнәтмәсе эч китүдән, күз ялкынсынудан файдалы. Сирень чәчәге баш авырту, веналарның варикоз киңәюеннән, җәрәхәтләрне дәвалау өчен кулланыла.

➢**КЫЧЫТКАН.** Май кычытканы бик шифалы, аны дәвалану өчен генә түгел, чирләрне кисәтү максатында да кулланырга кирәк. Ашын пешерегез, киптереп куегыз. Яшь кычыткан яфраклары үт суын куа, кан тамырларын киңәйтә, ялкынсынудан ярдәм итә, гемоглобинны, организмның тонусын күтәрә, иммунитетны ныгыта.

➢**ӘРЕКМӘН.** Майда әрекмәннең тамырын һәм яшь яфракларын җыялар, ул онкология чирләреннән, ревматизм, буыннар сызлаудан кулланыла. Шешенү һәм варикоздан әрекмән яфрагы белән компресс ясарга була.

Тузганак

Ул тимер, фосфор, калий, А һәм С витаминнарына, шулай ук аксым кушылмаларына бай. Аның согында сидек кудыру тәэсиренә ия булган тараксациннын ачы матдәсе бар. Тузганак шикәр чире, үт куыгы һәм бавыр авыруларына, авитаминоз, анемиягә каршы көрәштә ярдәм итә. Тузганакны әллә ничә төрле максатта кулланырга мөмкин.

Хәлсезлектән. Ике чәй кашыгы вакланган тузганак тамырын һәм үләнен 1 стакан кайнар суда 1 сәгать төнәтеп сөзегез. Шуны ашарга 30 минут кала көнгә дүрт тапкыр чирек стакан эчегез.

Йокысызлыктан, нерв киеренкелегеннән, витамин җитмәүдән. Яңа әзерләнгән тузганак согын (50 мл), ашарга 30 минут кала, көнгә ике тапкыр өч атна дәвамында эчегез.

Хәтер начараюдан һәм атеросклероздан. Тузганак тамырыннан яңа гына әзерләнгән сокны һәм дөге кайнатмасын бергә-бер (1:1) күләмдә кушып, ашарга 30 минут кала, көнгә өч-дүрт тапкыр 50 мл эчегез.

Бөердә һәм сидек куыгында таш, ком һәм башка авырулар булганда, симергәндә, эч күпкәндә, эч катканда, суалчаннардан котылу өчен, төнәтмәне түбәндәгечә ясап эчәргә кирәк: вакланган 2 чәй кашыгы тузганак тамырын 1 стакан суга салып, 8 сәгать салкын урында тотып, сөзегез һәм көнгә берничә тапкыр эчегез.

ТУЗГАНАК САЛАТЫ

Яфрагын чистартып, салкын су белән юалар да өстенә кайнар су салалар, иләктә саркыткач, бармак киңлегендә аркылыга турап, тирәнрәк савытка бушаталар, чистартып, кайнар су белән юган йөзем, шикәр комы, каймак, тоз өстәп болгаткач, 10 минут салкында тоталар һәм, салат савытына салып, кырыен тузганак яфрагы, өстен дүрткә кискән пешкән йомырка белән бизиләр.
1 ӨЛЕШКӘ: 150 г тузганак яфрагы, 30 г йөзем, 10–15 г шикәр комы, 1 йомырка, 50 г каймак, кирәгенчә тоз.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ
Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – **Гөлгенә ШИҺАПОВА**. Биткә салучы һәм бизәүче – **Рөстәм МИҢНУЛЛИН.**
Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 5 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru